ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге составына керүче Никифорово торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

№ 3 30 октябрь 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авылҗирлегенең Никифорово торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Никифорово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 елда 500 (биш йөз)сумм күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
-Никифорово торак пунктындагы Ленин урамы юлларны ремонтлау
- Никифорово торак пунктындагы урам утларын карап төзәтеп тору
-Никифорово торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту

3. Әлеге карарны Никифорово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислекитүче,
Мамадыш муниципаль районы
НикифоровоавылҗирлегеБашлыгы,
Совет рәисе С.Н.Степанов